| Республика Татарстан<br>Совет Азалаковского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Азалак авыл җирлеге Советы |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.03.2026 ел №19

Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 07.11.2014 ел, № 17 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Совет Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлеге советы кара итте:

1. Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 07.11.2014 ел, № 17 карарына ( 29.05.2015ел, N 11; 20.06.2018 ел, N 7; 12.11.2018 ел, N 22; 20.03.2020 ел. N 3; 01.11.2024 ел, N 13; 22.11.2024 ел, N 18а; 16.12.2025 ел, № 10; 30.12.2025 ел, №15; 20.02.2026ел, № 17) карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

   «2 пунктның 2.4.3 пунктчасында «, проектлана торган, билгеләнеше күпфатирлы йорт булган, төзелеп бетмәгән объектлардан тыш» сүзләрен өстәргә;».
2. Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының «Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 07.11.2014 ел, № 17 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 20.02.2026 ел, № 17 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе
Азалак авыл җирлеге
Сарман муниципаль районы Габдулгазизов И.Г.